# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Бутлеровка авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 елның 12 апреленнән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегенең Бутлеровка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 31 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 111 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 68 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 65 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 3 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегендәге Бутлеровка авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa: «Сез Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегенең Бутлеровка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 31 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәл Бутлеровка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы И.Л. Хушанова